**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№9065**
**04.09.2026**

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең
шәһәр һөнәри осталык конкурсын
әзерләү һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2025 елның 29 октябрендәге 8855 номерлы Карары белән расланган «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең кадрлар потенциалын саклау һәм үстерү, иҗади эшләүче шәхесләрне ачыклау һәм аларның эшчәнлеген стимуллаштыру, аларның һөнәри һәм карьера үсешенә ярдәм күрсәтү, һөнәрнең престижын популярлаштыру һәм күтәрү максатларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә 2026 елның сентябрь - декабрендә яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрергә (алга таба - конкурс).
2. Расларга:
1) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;
2) конкурс үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.
3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына, 3 нче кушымтада каралганча 243 800 (ике йөз кырык өч мең сигез йөз сум) 00 тиен күләмендә тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 4 сентябрендәге
9065 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри
осталык конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсы (алга таба - конкурс) әлеге өлкә хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм һөнәрнең престижын күтәрүгә, Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт яшьләр сәясәтен инновацион үстерүгә һәм модернизацияләүгә юнәлдерелгән.

2. Конкурс яшьләр белән эшләү өлкәсендәге уңышларны демонстрацияләү мәйданчыгы булып тора һәм Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең үсеш стратегиясен билгели.

3. Конкурс тармакның кадрлар потенциалының һөнәри компетентлылыгын һәм осталыгын формалаштыру юлы аша яшьләр белән яңа дәрәҗәдә сыйфатлы эшләүгә ирешүгә юнәлдерелгән.

2 бүлек. Конкурсның максаты һәм бурычлары

4. Конкурсның максаты – Яр Чаллы шәһәрендә тармакны инновацион үстерүне тәэмин итү өчен яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче талантлы җитәкчеләр һәм белгечләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү.

5. Конкурсның бурычлары:

1) яшьләр сәясәте хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын, престижын һәм социаль статусын күтәрү;

2) һөнәри әзерлек дәрәҗәсен, инновацион потенциалны бәяләү һәм күтәрү;

3) инновацион программалар һәм проектлар булдыру һәм аларны тормышка ашыруны стимуллаштыру;

4) яшьләр сәясәте өлкәсендә үзләрен уңышлы лидерлар итеп күрсәткән талантлы яшь хезмәткәрләрне ачыклау һәм аларның алга таба һөнәри үсешенә ярдәм күрсәтү;

5) яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыру, шул исәптән кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эш тәҗрибәсе белән уртаклашу өчен мәйданчыклар булдыру;

6) яшьләр сәясәтен тормышка ашыру мәсьәләләренә җәмәгатьчелек һәм барлык дәрәҗәдәге хакимият органнары игътибарын җәлеп итү.

3 бүлек. Конкурсны оештыручылар

6. Конкурсны оештыручылар:

1) Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;

2) Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе;

3) Яр Чаллы шәһәренең «Диалог» балалар һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе.

7. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) заявкаларны кабул итә;

2) конкурс сынауларын үткәрүне оештыра;

3) конкурска йомгак ясый.

4 бүлек. Конкурс номинацияләре

8. Әлеге нигезләмә белән түбәндәге төп конкурс номинацияләре билгеләнә:

1) «Яшьләр сәясәте учреждениесе командасы» номинациясендә яшьләр сәясәте учреждениесе җитәкчесе һәм белгечләреннән торган дүрт кешедән торган командалар катнаша:

- «Патриотик эш буенча яшьләр сәясәте учреждениесенең иң яхшы командасы» (патриотик тәрбия программалары буенча эш белән шөгыльләнүче учреждениеләр өчен) юнәлешендә;

- «Ихтыяри ярдәм эшчәнлеге буенча яшьләр сәясәте учреждениесенең иң яхшы командасы» (гуманитар миссия, эко-волонтерлык, зооволонтерлык, мәдәни, вакыйгалы, патриотик, инклюзив, медиа һәм социаль волонтерлык, хәйриячелек һәм башкалар белән шөгыльләнүче учреждениеләр өчен) юнәлешендә;

- «Гомуми юнәлештәге яшьләр сәясәте учреждениеләренең иң яхшы командасы» юнәлешендә;

- «Профилактика эше буенча яшьләр сәясәте учреждениесенең иң яхшы командасы» (яшьләр арасында профилактика эшчәнлеге программалары буенча эш белән шөгыльләнүче учреждениеләр өчен) юнәлешендә;

2) «Профессионаллар вакыты: яшьләр белән эшләү технологияләре» (индивидуаль номинация). Номинациядә катнашалар:

- Яр Чаллы шәһәрендә яшьләр сәясәтен тормышка ашыручы яшьләр сәясәте учреждениеләре, шулай ук аларның структур бүлекчәләре белгечләре.

«Профессионаллар вакыты: яшьләр белән эшләү технологияләре» номинациясе юнәлешләре:

- ихтыяри ярдәм;
- патриотик тәрбия;
- яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм эшкә урнаштыру;
- иҗат эшчәнлеге;
- студентлык;
- эшләүче яшьләр;
- җәмәгать оешмалары;
- «Алдынгылар хәрәкәте»;
- медиа һәм башка юнәлешләр.

## 5 бүлек. Конкурста катнашучылар

9. Конкурста яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең җитәкчеләре һәм белгечләре катнаша.

## 6 бүлек. Конкурста катнашу өчен документлар һәм аларны рәсмиләштерүгә таләпләр

10. Конкурста катнашу өчен конкурсантлар түбәндәге документларны тапшыралар:

1) «Яшьләр сәясәте учреждениесе командасы» номинациясендә катнашучылар өчен әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча заявка, «Профессионаллар вакыты: яшьләр белән эшләү технологияләре» (индивидуаль номинация) номинациясендә катнашучылар өчен әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча заявка;

2) «Молодежь России» АИС автоматлаштырылган мәгълүмат системасында конкурста катнашучының тутырылган заявкасы www.ais.fadm.gov.ru (системада теркәлмәгән очракта, алдан теркәлү узарга кирәк), барлык номинацияләрдә катнашучылар өчен;

3) барлык номинацияләрдә катнашучылар өчен әлеге нигезләмәнең 3 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

4) «Яшьләр сәясәте учреждениесе командасы» номинациясендә катнашучылар өчен әлеге нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган форма буенча яшьләр сәясәте учреждениесенең эш моделе тасвирламасы;

5) «Профессионаллар вакыты: яшьләр белән эшләү технологияләре» номинациясендә катнашучылар өчен әлеге нигезләмәгә 5 нче кушымтада каралган форма буенча катнашучының резюмесы;

6) «Профессионаллар вакыты: яшьләр белән эшләү технологияләре» номинациясендә катнашучылар өчен 6 нчы кушымтада

каралганча шәһәрдә яшьләр сәясәтен үстерүгә юнәлдерелгән авторлык программасы (проект);

7) «Профессионаллар вакыты: яшьләр белән эшләү технологияләре» номинациясендә катнашучылар өчен форма буенча эш урыныннан белешмә.

11. Авторлык программалары (проектлары) юнәлешләренең исемлеге:

1) яшьләрне патриотик тәрбияләү;

2) иҗтимагый оешмалар һәм хәрәкәтләргә ярдәм күрсәтү һәм үзара эшчәнлек;

3) халыкара һәм регионара яшьләр хезмәттәшлеген үстерү;

4) яшьләрне ихтыяри ярдәм һәм волонтерлык эшчәнлегенә җәлеп итү;

5) яшьләрне сәламәт яшәү рәвеше алып баруга һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү; яшьләр мохитендә иминлек культурасын популярлаштыру;

6) яшьләрне инновацион эшчәнлеккә һәм фәнни-техник иҗатка җәлеп итү;

7) яшьләрне массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләүгә җәлеп итү (яшьләр медиасы);

8) социаль-куркыныч хәлдәге яшьләр белән эшләү;

9) яшьләр үзидарәсен үстерү;

10) яшьләрнең профориентациясенә һәм карьера омтылышларына ярдәм күрсәтү;

11) Россия тәңгәллеген, Россия милләте бердәмлеген формалаштыру, мәдәниятара һәм конфессияара диалогка ярдәм күрсәтү;

12) яшьләрне иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнүгә җәлеп итү;

13) дәүләтнең аеруча яклавына мохтаҗ яшьләрне социальләштерү;

14) яшьләрдә традицион гаилә кыйммәтләрен формалаштыру;

15) яшьләр сәясәте өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм кабаттан әзерләүгә ярдәм күрсәтү;

16) балалар һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү.

12. Шәһәрдә яшьләр сәясәтен үстерүгә юнәлдерелгән авторлык программасы (проекты) түбәндәге таләпләр нигезендә үтәлергә тиеш:

1) A4 форматындагы ак кәгазь битләре (ориентация – китап бите);

2) Times New Roman шрифты, төсе — кара, үлчәме 14, гадәти, исемнәре — үлчәме 16, каралтылган;

3) төп текстны тигезләү – киңлеген, абзац арасын – 1,5, исемнәрне тигезләү – үзәк буенча;

4) битләрнең саннарын кую – аста, уң як кыр буйлап (титул биттә бит саны куелмый);

5) кырлары: сулда – 30 мм, өстә, уңда – 20 мм.

Программа (проект) бер документка тупланган (брошюраланган) булырга тиеш.

13. Авторлык программасы (проект) элементларының структур элементлары:

1) титул бите әлеге нигезләмәнең 6 нче кушымтасындагы форма буенча;

2) эчтәлек (программаның (проектның) төп пунктларының исемнәре, бит номерларын күрсәтеп);

3) кереш сүз:

- программаның (проектның) актуальлеге;
- программаның (проектның) яңалыгы;
- программаның (проектның) юнәлешлелеге;
- әлеге программаның (проектның) булган программалардан (проектлардан) аерым үзенчәлеге;
- программаның (проектның) максатчан аудиториясе – катнашучыларның яше, социаль статусы;
- программаның (проектның) максаты;
- программаның (проектның) бурычлары;
- программаны (проектны) гамәлгә ашыру срогы;
- программаның (проектның) дәвамлылыгы;
- хәзерге вакытта программаны (проектны) гамәлгә ашыруның стадиясе;

4) программаны (проектны) гамәлгә ашыруның эчтәлеге һәм технологияләре (механизмы һәм этаплап гамәлгә ашыру планы);

5) программаны (проектны) ресурслар белән тәэмин итү (финанс, кадрлар, матди-техник һәм башкалар);

6) мониторинг нәтиҗәләрен (әгәр программа (проект) гамәлгә ашырыла икән), көтелгән нәтиҗәләрне (гамәлгә ашырырга планлаштырылган программалар (проектлар) өчен) күрсәтеп, программаның (проектның) нәтиҗәлелек дәрәҗәсен анализлау һәм бәяләү;

7) кулланылган әдәбият исемлеге;

8) кушымталар (фотографияләр, нәтиҗәлелекне раслау һәм башкалар — конкурста катнашучының ихтыярында).

14. Авторлык программаларын (проектларын) бәяләү критерийлары (0 дән 5 баллга кадәр):

1) структурасы һәм рәсмиләштерүе буенча таләпләргә туры килү;

2) программаның (проектның) дәүләт яшьләр сәясәте юнәлешенә туры килүе (тәңгәллеге);

3) максатчан аудитория өчен программаның (проектның) актуальлеге, аның яңалыгы (булганнарыннан аермасы);

4) программаның (проектның) максатын һәм бурычларын формалаштыруның ачыклыгы;

5) программаның (проектның) сыйфаты: тулылыгы, стиле, логикага нигезләнгән булуы;

6) программаны (проектны) тормышка ашыру тәҗрибәсе булу;

7) программаны (проектны) кирәкле ресурс белән тәэмин итү;

8) программаның (проектның) нәтиҗәлелек дәрәҗәсен анализлау һәм бәяләү, нәтиҗәләрне күрсәтеп;

9) нәтиҗәләрнең куелган бурычларга туры килүе;

10) программаның (проектның) нәтиҗәлелеген күзәтеп була торган индикаторлар булу.

## 7 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм сроклары

15. Конкурс түбәндәге этаплардан тора:

1) читтән торып (оештыру комитеты тарафыннан заявкаларны кабул итү һәм карау, материалларны карап тикшерү);

2) урында;

3) финал.

16. Конкурста катнашуга заявкалар һәм аңа теркәлгән материаллар 2026 елның 10 сентябреннән 2026 елның 25 сентябренә кадәр Яр Чаллы шәһәре, Цветочный бульвары, 1А (20/07А), 19 кабинет адресы буенча «Заман» яшьләр үзәге» МАУда кабул ителә.

17. Материаллар конкурсны оештыру комитеты тарафыннан 2026 елның 28 сентябреннән 2026 елның 2 октябренә кадәр карап тикшерелә.

18. Урындагы этап түбәндәге сынаулардан тора:

1) барлык номинацияләрдә катнашучылар өчен Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәтен белүгә тест (балларның саны сорауларга дөрес җаваплар саны белән билгеләнә);

2) 2026 елның 25 сентябреннән 2026 елның 31 октябренә кадәр барлык номинацияләрдә катнашучылар өчен стратегик сессияләр.

19. Финал үз эченә ала:

1) конкурста катнашучының телдән чыгышы («Минем визит карточкам» үз-үзен презентацияләү);

2) авторлык программасын/проектын яклау, яшьләр сәясәте учреждениесенең эш моделен тасвирлау.

20. «Минем визит карточкам» үз-үзеңне презентацияләүгә таләпләр:

«Минем визит карточкам» – конкурста катнашучының компьютер презентациясен яки видеороликны кулланып, үз-үзен презентацияләве, ул конкурсантның үзе һәм үзенең һөнәри казанышлары, һөнәренә мөнәсәбәте турында иҗади күзаллау булып тора, конкурсантның эшен һәм үзен һөнәрендә ничек күзаллавын күрсәтә. Үз-үзеңне презентацияләү конкурсант турында фикер формалаштыруга ярдәм

итәргә тиеш. Материалны оригиналь һәм кызыклы итеп бирергә тәкъдим ителә.

21. Компьютер презентациясенә техник таләпләр:

1) компьютер презентациясе Power Point программасында .ppt, .pptx ны киңәйтү белән башкарылырга тиеш;

2) слайдларның минималь саны — 10;

3) беренче бит — титул бите, анда катнашучының фамилиясе һәм исеме, оешманың тулы исеме, биләгән вазыйфасы күрсәтелергә тиеш;

4) дизайн – эргономик таләпләр: төсләрнең ярашуы, слайдтагы объектларның чикләнгән саны, текстның төсе. Презентация бердәм стильне сакларга тиеш (төс, шрифт-үлчәм, язу, тигезләү).

22. Видеороликларга техник таләпләр:

1) видеороликны фильмнар төшерү буенча теләсә кайсы программада төшерергә мөмкин;

2) беренче кадрда конкурста катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, эш урыны һәм вазыйфасы булырга тиеш;

3) видеоның озынлыгы 2 минуттан артмаска тиеш.

23. «Минем визит карточкам» үз-зеңне презентацияләүне бәяләү критерийлары (0 дән 3 баллга кадәр):

1) рәсмиләштерү һәм эчтәлек буенча таләпләргә туры килү;

2) теманы ачуның тулылыгы, материалның мәгълүматлылыгы;

3) материалны бизәү һәм тәкъдим итүгә иҗади караш;

4) материалның эчтәлеге һәм форма оригинальлеге, сюжет линиясе динамикалылыгы;

5) эш башкаруның сыйфаты (композиция, төсләр чишелеше, грамоталылык һәм бизәүнең пөхтәлеге).

24. Конкурста катнашучының телдән чыгыш ясавына куела торган таләпләр.

Конкурста катнашучы чыгышының вакыт регламенты, үз-үзен презентацияләүне дә кертеп, 5 минуттан артмаска тиеш.

Конкурсантның халык алдында чыгыш ясау культурасы, аның сөйләме, үз-үзен тотышы, тышкы кыяфәте бәяләнергә тиеш. Конкурста катнашучы гомуми һәм профессиональ культурасын һәм эрудициясен күрсәтергә, үз позициясен төгәл һәм грамоталы итеп аңлатырга, бирелгән сорауларга адекват һәм эчтәлекле җавап бирергә, артистлык һәм коммуникатив сыйфатлар күрсәтергә тиеш.

25. Конкурста катнашучыларга ярдәм күрсәтү йөзеннән команда-төркемнәр катнашуга уңай карала, финалда алар өчен блиц-сораштыру оештырылачак.

## 8 нче бүлек. Конкурска йомгак ясау

26. Конкурс сынауларында катнашу нәтиҗәләре буенча һәр номинациядә җиңүчеләр (беренче урынны алган катнашучылар) һәм

призерлар (икенче һәм өченче урыннарны алган катнашучылар) билгеләнә.

27. Конкурс җиңүчеләре һәм призерлары оештыру комитеты тарафыннан конкурс сынауларын узу нәтиҗәсендә, конкурсантлар җыйган баллар суммасы буенча билгеләнә. Баллар суммасы тигез булган очракта, җиңүчеләрне һәм призерларны билгеләгәндә оештыру комитеты рәисенең тавышы хәлиткеч була. Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

28. Конкурс җиңүчеләре һәм призерлары дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә.

29. Конкурс җиңүчеләре Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең республика һөнәри осталык конкурсында катнашу өчен җибәрелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри
осталык конкурсында катнашуына
заявка

____________________________________________________________

(оешма исеме)

яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсында катнашуга җибәрә

____________________________________________________________

номинация исеме

| № т/б | Командада катнашучының Ф.И.А.и. | Катнашучының вазыйфасы һәм эш урыны | Катнашучының элемтә телефоны |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| 4. | | | |

Конкурс документларының составы:

____________________________________________________________

Оешма җитәкчесе

М.У.

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри
осталык конкурсында катнашуына
заявка

____________________________________________________________________

(оешма исеме)

яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсында катнашуга җибәрә

____________________________________________________________________

номинация исеме

______________________________________________________________

(конкурсантның Ф.И.А.и., эш урыны, вазыйфасы)

______________________________________________________________

(проектның (программаның исеме)

Конкурс документларының составы:

____________________________________________________________________

Оешма җитәкчесе

М.У.

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Яшьләр сәясәте хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри конкурсын оештыру комитетына
кемнән_______________________________________

______________________________________________

______________________________________________

адресы буенча яшәүче:

_____________________________________________

_____________________________________________

_____________________________________________

паспорт (номеры һәм сериясе, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)__________________________________

_____________________________________________

_____________________________________________

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин,

__________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Заман яшьләр үзәге» МАУ һәм Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының яшьләр белән эшләү идарәсенә дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең һөнәри осталыгы конкурсында катнашу өчен тәкъдим ителгән һәм Россия Федерациясе законнарын үтәүне тәэмин итү максатларында, иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү, минем тормышымның фактлары, вакыйгалары һәм шартлары турында мәгълүматлар булган шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә үз ризалыгымны бирәм.

Әлеге ризалык имзаланган көннән башлап аны язма рәвештә соратып алган көнгә кадәр гамәлдә.

____________________ _______________________ ____________________________

(дата) (имза) (расшифровка)

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

Яшьләр сәясәте учреждениесенең эш моделе тасвирламасы

1. Учреждениенең исеме.
2. Учреждение миссиясе (максатлар һәм бурычлар).
3. Максатчан аудитория.
4. Учреждение эшенең принциплары.
5. Норматив-хокукый база.
6. Учреждение эшчәнлегенең төп юнәлешләре.
7. Учреждениенең оештыру структурасы (учреждениенең типик структурасы).
8. Тормышка ашыру механизмнары.
9. Эш формалары һәм методлары.
10. Ресурслар белән тәэмин итү (кадрлар, финанс, материаль – техник база, мәгълүмати һәм башкалар).
11. Нәтиҗәлелекне бәяләү:

Бәяләү критерияләры:

- елга җәлеп ителгән яшьләр саны;
- тормышка ашырылган яшьләр проектларының саны;
- иҗтимагый берләшмәләр саны;
- түгәрәкләр һәм секцияләр саны;
- чараларның медиа яктан таралуы;
- яшьләрнең шәһәр, республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, чараларда, форумнарда (шул исәптән җиңүләрдә) катнашулары һәм казанышлары;
- сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән яшьләр белән эшләү (җәлеп итү);
- исәпнең төрле төрләрендә торучы яшьләр белән эшләү.

12. Алдагы 3 елга учреждениене үстерү концепциясе.

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри
осталык конкурсында катнашучы
резюмесы

<table>
<tr><td>Фамилиясе, исеме, атасының исеме</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>Туган көне, ае, елы</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>Туган урыны</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>Өй адресы, телефоны, e-mail</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>Гаилә хәле</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>Эш урыны, вазыйфасы</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td rowspan="8">Белеме</td><td colspan="2">Белем бирү учреждениесенең тулы исеме, укырга керү/тәмамлау датасы</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Факультеты</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Белгечлеге</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Белгечлек буенча эшләве</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Өстәмә белем алуы: курслар, стажировкалар, исемнәрен күрсәтеп (мөһимлеге тәртибендә)</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Икенче югары белем (белем бирү учреждениесенең тулы исеме, укырга керү/тәмамлау датасы</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Аспирантура, докторантура, белгечлекне күрсәтеп, укырга керү/тәмамлау датасы</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Гыйльми дәрәҗәсе</td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="4">Эш тәҗрибәсе</td><td rowspan="2">00.00-00.00 (елы, ае)</td><td>Оешма исеме (эшчәнлек өлкәсе)</td><td></td></tr>
<tr><td>Вазыйфасы (яисә статусы)</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Вазыйфалары (әһәмиятлерәк моментлар күрсәтелгән исемлек)</td><td></td></tr>
<tr><td>00.00.00-00.00.00</td><td>Оешма исеме (эшчәнлек өлкәсе)</td><td></td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (елы, ае) | | |
| | Вазыйфасы (яисә статусы) | | |
| | Вазыйфалары (әһәмиятлерәк моментлар күрсәтелгән исемлек) | | |
| Тутыру вакыты | | | |
| Шәхси имзасы | | | |

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта

Конкурста катнашучы авторлык программасының (проектының) титул бите үрнәге

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең
шәһәр һөнәри осталык конкурсы
(шрифт Times New Roman, үлчәме 14-калын, юл хәрефләре,
уртада тигезләү)
Конкурста катнашуга тәкъдим иткән учреждениенең
(учреждениеләрнең) исеме
(шрифт Times New Roman, үлчәме 14-гадәти, юл хәрефләре,
уртада тигезләү)

ПРОГРАММАНЫҢ (ПРОЕКТНЫҢ) ИСЕМЕ
(шрифт Times New Roman, үлчәме 16, калын, юл хәрефләре,
уртада тигезләү)
Дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлеше
(шрифт Times New Roman, үлчәме 14 - гадәти, юл хәрефләре,
уртада тигезләү)

Ф.И.А.и. (тулысынча), вазыйфасы
(шрифт Times New Roman, үлчәме
14-гадәти, юл хәрефләре,
уң як буенча тигезләү)

2026

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
7 нче кушымта

Белешмә учреждение бланкында бирелә

БЕЛЕШМӘ

____________________________________________________бирелде һәм аның чыннан да ________ башлап бүгенге көнгә кадәр ______________________________________________ __________________________________________________ вазыйфасында эшләвен раслый.
Вазыйфаи бурычлар даирәсенә түбәндәге эшчәнлек төрләре керә, алар номинация тематикасы буенча тиешле тәҗрибә булуын раслый, атап әйткәндә:
- эшчәнлек һәм эш бурычларын тасвирлау.

Оешма җитәкчесе

М.У.